**СОВЕТ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

08.12.2021 с. Сарманово № 62

**«2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы Сарман районы муниципаль районы бюджеты турында»**

Сарман районы Советы карар итте:

1 статья

1. 2022 елга Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең фаразланыла торган гомуми күләме 1 093 583,2 мең сум;

2) Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 1 093 583,2 мең сум.;

3) Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы бюджеты дефициты күләме 0,0 мең сум

2. 2023 елга һәм 2024 елга Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) 2023 елга Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы бюджетының фаразланыла торган гомуми керем күләме 1 111 437,3 мең сум һәм 2024 елга 1 117 697,5 мең сум күләмендә фаразлана;

2) 2023 елга Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы бюджетының гомуми чыгымнары күләме 1 111 437,3 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 11 000,0 мең сум күләмендә һәм 2024 елга 1 117 697,5 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 23 000,0 мең сум күләмендә;

3) Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы бюджетының дефициты 2023 елга 0,0 мең сум һәм 2024 елга 0,0 мең сум күләмендә.

3. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының 2022 елга һәм 2023, 2024 еллар план чорына бюджет дефицитын финанслау чыганакларын әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2 статья

1. 2023 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы муниципаль эчке бурычының иң югары чиген 0,0 мең сум күләмендә, шул исәптән Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы муниципаль

гарантияләре буенча Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы муниципаль эчке бурычының иң югары чиген 0,0 мең сум күләмендә расларга.

2. 2024 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы муниципаль эчке бурычының иң югары чиген 0,0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы муниципаль гарантияләре буенча Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы муниципаль эчке бурычының иң югары чиген 0,0 мең сум күләмендә расларга.

3. 2025 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы муниципаль эчке бурычының иң югары чиген 0,0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы муниципаль гарантияләре буенча Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы муниципаль эчке бурычының иң югары чиген 0,0 мең сум күләмендә расларга.

3 статья

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы бюджетында, әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә, 2022 елга һәм 2023, 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы бюджетының фаразланучы керем күләмен исәпкә алырга.

4 статья

2022 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы бюджетына 2021 ел йомгаклары буенча салымнарны түләгәннән һәм башка мәҗбүри түләүләрне башкарганнан соң калган Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының муниципаль унитар предприятиеләре табышының бер өлешен кертү күрсәтелгән табышның 30 проценты күләмендә 2022 елның 1 июленә кадәр башкарыла дип билгеләргә.

5 статья

1. 2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын әлеге Решениегә 3 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен 2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы муниципаль программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә расларга.

3. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен максатчан статьялар (Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы муниципаль программалары һәм программага карамаган эшчәнлек юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре, 2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына бюджет чыгымнары классификациясе бүлекләре, бүлекчәләре буенча бүлүне әлеге карарга 5 нче кушымта нигезендә расларга.

4. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы бюджетының 2022 елга 31 510,2 мең сум күләмендә, 2023 елга 30 957,9 мең сум күләмендә, 2024 елга 31 706,4 мең сум күләмендә бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен

расларга.

6 статья

Юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, физик затларга – товар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) җитештерүчеләргә әлеге карарда каралган субсидияләр Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Башкарма комитеты билгеләгән тәртиптә бирелә.

7 статья

1. Төзелгән килешүләр нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләр өлешен гамәлгә ашыру өчен җирлекләр бюджетларыннан Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы бюджетына күчерелергә тиешле башка бюджетара трансфертларның күләмен исәпкә алырга:

- торак фондын капиталь ремонтлау буенча әлеге карарга 7 нче кушымта нигезендә бүленеп, 2022 елга 9 126 мең сум, 2023 елга-9 126 мең сум, 2024 елга-9 126 мең сум. күләмендә;

- ял итүне оештыру һәм җирлекләрдә яшәүчеләрне мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру буенча әлеге карарга 7 нче кушымта нигезендә бүленеп, 2022 елга 58 799,1 мең сум, 2023 елга 61 065,2 мең сум, 2024 елга 63 416,6 мең сум күләмендә;

2. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл иткәндә җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы бюджетына күчерелергә тиешле субсидияләр күләмен әлеге карарга 8 нче кушымта нигезендә бүленеп, 2022 елга 27 339,6 мең сум күләмендә, 2023 елга 27 481,0 мең сум күләмендә, 2024 елга 27 995,0 мең сум күләмендә расларга;

3. 2022 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы бюджетына җирлекләр бюджетларыннан әлеге статьяда каралган субсидияләр һәм башка бюджетара трансфертлар квартал саен күчерелә дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарына җирлекләр бюджетларында субсидияләр һәм әлеге статьяда билгеләнгән башка бюджетара трансфертларны алдан исәпкә алырга.

8 статья

2022 елга җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә 46 876,1 мең сум, 2023 елга 47 739,2 мең сум, 2024 елга 48 769,0 мең сум күләмендә, әлеге карарга 9 нчы кушымта нигезендә бүленеп, дотацияләр күләмен расларга.

9 статья

2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына, 10 нчы кушымта һәм 11 нче кушымта нигезендә, җирлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу һәм беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирлекләр бюджетларына субвенцияләр күләмен расларга.

10 статья

2022 елга Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Юл фондының бюджет ассигнованиеләре күләмен 20 900,0 мең сум күләмендә расларга, 2023 елга 21 900,0 мең сум күләмендә, 2024 нче елга 22 000,0 мең сум күләмендә расларга һәм аларны 2022, 2023 һәм 2024 елларга Татарстан

Республикасы Сарман муниципаль районы гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре программасы чараларын гамәлгә ашыруга юнәлдерергә.

11 статья

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының җирле үзидарә органнары 2022 елда муниципаль хезмәткәрләр һәм муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләре санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел, моңа Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының җирле үзидарә органнарына, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының муниципаль казна учреждениеләренә яңа функцияләр яисә вәкаләтләр бирү белән бәйле карарлар кабул итү очракларыннан тыш.

2. Җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына 2022 елда муниципаль хезмәткәрләр һәм муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләре санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итмәскә киңәш итәргә.

12 статья

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы бюджетында 2022 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан 630 712,6 мең сум, 2023 елда 624 429,9 мең сум, 2024 елда 605 321,2 мең сум күләмендә алына торган бюджетара трансфертларны әлеге карарга 12 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга.

13 статья

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментының Сарман районы буенча территориаль бүлеге төзелгән килешүләр нигезендә Сарман муниципаль районы бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне башкара.

14 статья

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы бюджетының 2022 елның 1 гыйнварына калган акчалары Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы исеменнән төзелгән товарлар, эшләр башкару, хезмәт күрсәтүгә муниципаль контрактларның шартлары нигезендә 2021 елда түләнергә тиешле муниципаль контрактлар суммасыннан артмаган күләмдә, 2021 елда бирелгән юридик затларга субсидияләр бирү өчен бюджет ассигнованиеләре суммасыннан артмаган күләмдә, финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булган субсидияләр алучыларның акчалата йөкләмәләрен түләү өчен кирәкле булган акчалар 2022 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Башкарма комитеты тиешле карар кабул иткән очракта тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга юнәлдерелә.

15 статья

Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

16 статья

Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

17 статья

Әлеге карарның утәлешен контрольдә тотуны муниципаль район Советының бюджет-финанс мәсьәләләре, җирле салымнар һәм җыемнар буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Сарман муниципаль районы
Советы рәисе Ф.М.Хөснуллин